ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.10.2023 ел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48, 2

с. Татарское Бурнашево

**Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Юмат авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 27 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Юмат авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Юмат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез риза булырсызмы:

- сатучы хисабына товарны билгеләнгән пунктка илтеп җиткереп, Юмат авылына юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Чиркәү бинасы янында халык җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Юмат ав., Заречная ур., 39 й. 14.00 сәг.
4. Җыенны оештыручы итеп Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин